РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

Буа шәһәре

КАРАР

10 август 2026 ел

№ 1-17

Татарстан Республикасы Буа районының Боерган тимер юл разъезды поселогын бетерү, Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» һәм «Карлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү буенча Буа муниципаль районы Советының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Буа районының Боерган тимер юл разъезды поселогын бетерү мәсьәләсе буенча җирлекләр халкының муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан белдерелгән ризалыгын исәпкә алып, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» һәм «Карлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Боерган тимер юл разъезды поселогын бетерергә.
2. «Татарстан Республикасы Буа районының Боерган тимер юл разъезды поселогын бетерү, Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» һәм «Карлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын һәм аңа материалларны закон чыгару инициативасы тәртибендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертергә.
3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законы проектын караганда Буа муниципаль районы Советы вәкиле итеп Буа муниципаль районы башлыгын Р.Р. Камартдиновны билгеләргә.
4. Әлеге Карар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында

http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының рәсми сайтында http://buinsk.tatarstan.ru, адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Карлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (рәисе А.М. Сибгатуллин).

ТР Буа
муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов